КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

2025 ел, 31 гыйнвар г.Казань № б-172

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 ел, 19 август, б-1829 нчы боерыгына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. «Татарстан Республикасының Инвестиция-венчур фонды» коммерциягә карамаган оешмасы (алга таба – Фонд) һәм Венчурлы инвестиция ассоциациясенең түбәндәге тәкъдимнәрен кабул итәргә:

2025 елның 9 – 11 апрелендә Россия венчур форумын (алга таба – Форум) үткәрү турында;

«Цифрлы үсешкә ярдәм ассоциациясе» коммерциягә карамаган оешмасын Форумның күргәзмә экспозициясен оештыручы һәм Форум кысаларында, партнерлар җәлеп итеп, башка чараларны оештырудашчы итеп билгеләү турында;

«Идея» инновация-җитештерү технопаркы» ябык акционерлык җәмгыятен Форум кысаларында акселерация программасын оештыручы итеп билгеләү турында;

Фондны Форум операторы итеп билгеләү турында;

Фонд тарафыннан Форум чараларын оештыру чыгымнарын финанслауны тәэмин итү турында;

«Цифрлы үсешкә ярдәм ассоциациясе» коммерциягә карамаган оешмасы тарафыннан Форумының күргәзмә экспозициясен оештыру һәм башка чараларын оештыру чыгымнарын финанслау тәэмин ителү турында;

әлеге боерык белән расланган 2025 елда Россия венчур форумын әзерләү һәм үткәрү буенча республика оештыру комитеты составында:

Алексей Валерьевич Песошинның вазыйфасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Премьер-министры, Оештыру комитеты рәистәше»;

Рифкать Нургали улы Миңнехановның вазыйфасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт фәнни бюджет учреждениесе президенты, Оештыру комитеты рәистәше урынбасары (килешү буенча)»;

Республика оештыру комитеты составына Россия Федерациясе Фән һәм югары белем министры, оештыру комитеты рәисе Валерий Николаевич Фальковны (килешү буенча) кертергә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин